**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки**
**муниципаль районы**
**Югары Колчурино авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Верхнеколчуринского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422873, ТР, Әлки районы,
Югары Колчура авылы, Март 8
урамы, 21 йорт
Тел/Факс 8 (84346) 78014

422873, РТ, Алькеевский район,
с.Верхнее Колчурино, ул.8 Марта,
д.21
Тел/Факс 8 (84346) 78014

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 7 июне** **Югары Колчурино авылы** **13№**

Югары Колчурино авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2021 елның 13
апрелендәге «2021 - 2024 елларда
Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Югары Колчурино
авыл җирлегендә кече һәм урта
эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль
программасын раслау турында» 8
номерлы карарына үзгәрешләр кертү
хакында

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Югары Колчурино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге 8 номер белән расланган «2021 - 2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» графасында «Әлки муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшмәкәрләрнең үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен алмаштырырга:
«Җирле бюджет акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |

| | |
|---|---|
| Барлыгы | 4 |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5 нче бүлек өстәргә:
«5. Программаны финанслау:
Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына методик, консультацион-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук җирле бюджет акчалары исәбеннән финанс, мәгълүмати һәм башка ярдәм алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатларында түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сумнарда)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1»; |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

Югары Колчурино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Е.В.Краснова